ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.12.2018 г. Заинск № 1775

**2019 елга «Зәй муниципаль районы муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Татарстан Республикасының балаларга өстәмә белем бирүче туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирүче күпюнәлешле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында" 2009 елның 31 декабрендә 939 нчы номерлы карары белән һәм Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2019 нчы елга расларга:

"Зәй муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге һәм балаларга

өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының программаны тормышка ашыруга кушымта итеп бирелә торган норматив чыгымнарын;

балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар буенча төзәтү коэффициенты 0,5 күләмендә.

2. "Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесен тәэмин итәргә:

әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслау;

әлеге карарның 1 пунктында расланган Балаларга өстәмә белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла торган өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы индексы белән бер үк вакытта яңадан карау.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Башкарма комитетның оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районы массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А. В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Г.М. Зиганшина
3-52-91

Зәй муниципаль районы Башкарма
комитетының 2018 елның 4 нче декабрендәге
№ 1775 карары белән расланган

**«Зәй муниципаль районы» балаларга өстәмә белем бирү оешмаларында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурологик юнәлешле балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлеше | Территориаль дислокация | Норматив чыгымнар,бер укучыга бер елга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче ел укыту | икенче ел укыту | өченче һәм алдагы елларда укыту |
| Эстетик-сәнгать | шәһәр җирлеге | 5 569 | 10 314 | 12 376 |
| | авыл җирлеге | 5 970 | 11 055 | 13 266 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 5 468 | 10 126 | 12 151 |
| | авыл җирлеге | 5 868 | 10 867 | 13 041 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 5 873 | 10 876 | 13 051 |
| | авыл җирлеге | 6 273 | 11 617 | 13 940 |
| Туристлык-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Экологик-биологик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 5 266 | 9 751 | 11 702 |
| | авыл җирлеге | 5 666 | 10 493 | 12 591 |
| Табигый | шәһәр җирлеге | 5 671 | 10 501 | 12 601 |
| | авыл җирлеге | 6 071 | 11 242 | 13 491 |